| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ | | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА ТАКТАЛАЧУКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АКТАНЫШСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА |
|---|---|---|
| 423751,Такталачык авылы,<br>Г.Авзал ур., 48 нче йорт.<br>Тел.3-44-57 | | 423751, село Такталачук,<br>ул.Г.Авзал,дом 48,<br>Тел. 3-44-57 |

**Карар**
**05.11.2019ел.**

**Постановление**
**№18**

Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлегенең Такталачык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Такталачык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Такталачык авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 17 ноябрендә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- оештыру ритуаль хезмәтләр һәм күмү урыннарын карап тору;
- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру.
- автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
-авыл җирлегендә яшәүчеләргә массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күплэп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру.

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Такталачык авылы, Г.Авзал урамы, 50 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Такталачык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.С.Шамсунов

Совет Такталачукского сельского поселения